**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН ТАБЫН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ XIV УТЫРЫШЫ**

*Югары Табын авылы* *"21" октябрь 2021 ел*

**К А Р А Р № 27**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Түбән Табын авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның «03» июль 5 номерлы Түбән Табын авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, шулай ук блокланган торак төзелеше өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләренең минималь күләмен 1 000 кв. м күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Совет рәисе, Түбән Табын авыл җирлеге башлыгы** **Р.Ш. Кыяметдинов**